Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

30 октябрь 2020 ел № 9

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2019 елның 16 декабрендәге 179 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Ачыклау тәртибендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2019 елның 16 декабрендәге 179 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертргә:

Карарга 1 нче кушымтада:

2 бүлекнең 2.1 пунктында «муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны тоту өчен шартлар тудыру» сүзләрен «социаль - мәдәни юнәлешле учреждениеләрне карап тоту буенча» сүзләренә алмаштырырга.»;

3.1 пунктын төшереп калдырырга;

3.2 пунктта «һәм Финанс-бюджет палатасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 2 һәм 3 пунктларында «муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны тоту өчен шартлар тудыру» сүзләрен «социаль - мәдәни юнәлешле учреждениеләрне карап тоту буенча» сүзләренә алмаштырырга;

Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 1.1 пунктында «муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны тоту өчен шартлар тудыру» сүзләрен «социаль - мәдәни юнәлешле учреждениеләрне карап тоту буенча» сүзләренә алмаштырырга;

Килешүгә 1 нче кушымтада «муниципаль мәгариф учреждениеләрендә

балаларны тоту өчен шартлар тудыруга» сүзләрен «социаль - мәдәни юнәлешле учреждениеләрне карап тоту буенча» сүзләренә алмаштырырга.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник», газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет - финанс мәсьәләләре буенча шәһәр Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов